**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 4 сентябрендәге 3765 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Яңа Савин районындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 686 кв.м;
- үзенә карата чикләүләр кертелә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:50:110803:7, 16:50:110803:2873, 16:50:110803:2567, 16:50:110803:2912;
- урнашкан урынын тасвирлау: Казан шәһәре, Яңа Савин районы;
- билгеләүнең максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: 5 ел;

1.2. гариза бирүче: «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе (ОГРН 1071690066744, ИНН 1655147246, урнашу урыны адресы: 420015, Казан шәһәре, Театр урамы, 13 йорт);

1.3. билгеләүнең нигезләре: гариза бирүченең гаризасы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 4
сентябрендәге 3765
номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**16:50:110803:2567, 16:50:110803:7, 16:50:110803:2873, 16:50:110803:2912 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:1000

Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары |
| 16:50:110803 | кадастр кварталы |
| 16:50:110803:2567, 16:50:110803:7, 16:50:110803:2873, 16:50:110803:2912. | үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |